РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Микулинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.АМикулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы. 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «28» 10.2022ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Дмитриевка торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәлә себуенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федеральзаконның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Дмитриевка авылында сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елның 9 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

1.2 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Дмитриевка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыен уздыру вакыты – 9 ноябрь 2022 ел 16.00 сәг.тән 17.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны – Дмитриевка авылы, Тургай ур.5нче йорт;

1.3 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдими итәргә:

- 2022 елның 28 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Дмитриевка авылы, Тургай ур.5 нче йорт;

- Дмитриевка торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Дмитриевка торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Микулино авыл җирлеге Дмитриевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашу чылардан, Бөек Ватан сугышынд катнашу чыларның тол хатыннарыннан, көндезгеуку формасында укучы студентлардантыш, 350 сумкүләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 175 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кыш көне юлларны кардан чистарту (килеш буенча түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Микулин авылы, Совет ур., 74 йорт, Дмитриевка авылы, Тургай ур.5нче йорт, адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: И.А.Такиулин